СОВЕТ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2025 с. Сарманово № 20

**Сарман муниципаль районы Советының 2018 елның 14 маендагы 122 номерлы карарына муниципаль берәмлекләр башлыкларының, Сарман муниципаль районы муниципаль берәмлекләре башлыкларының урынбасарларының, Сарман муниципаль районы контроль-хисап палатасы рәисенең айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында**

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 25.11.2025ел 994 номерлы карары, «Җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 182 номерлы карарына, муниципаль берәмлекләрнең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары, Сарман муниципаль районы Уставы, Сарман муниципаль районы Советына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Советының 2018 елның 14 маендагы 122 номерлы карарына (Сарман муниципаль районы контроль-хисап палатасы рәисе, Сарман муниципаль районы башлыкларының, урынбасарларының хезмәт хакының иң чик күләмнәрен раслау турында) 122 номерлы карарына (Сарман муниципаль районы Советының 2018 елның 16 ноябрендәге 148 номерлы, 07.09.2020, № 252, 10.12.2022, № 18, 14.09.2022, № 99, 12.2022, № 115, 20.05.2024, № 221, 05.2024, № 235, 2024 елның 24.04 № 260) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. «Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, Сарман муниципаль районы муниципаль берәмлекләре башлыклары урынбасарларының, Сарман муниципаль

районы контроль-хисап палатасы рәисенең хезмәт хакының иң чик күләмнәрен» 1 нче кушымтаның 1 пунктындагы 1 абзацын Сарман муниципаль районы Советының 2018 елның 14 маендагы 122 номерлы карарына түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата түләү күләмнәре:

| Вазифа исеме | Айлык акчалата түләү, сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 8 төркем* | 9 группа* | 10 группа* | 11группа* | 12 группа* |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы | 44 814 | 31 496 | 27 601 | 25 401 | 23 201 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 40 334 | 25 119 | 20 565 | 18 254 | 16 931 |
| Депутат | 21 977 | 16 928 | 16 928 | 16 928 | 16 928 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы | 19 674 | 16 928 | 16 928 | 16 928 | 16 928 |
| Контроль-хисап органы рәисе | 40 334 | | | | |

».

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Җирле үзидарә органнары һәм муниципаль орган җитәкчеләренә үзләре чыгарган хокукый актларны әлеге карарга туры китерүне йөкләргә.

4. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

5. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында әлеге карарны игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сарман муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Совет рәисе

Ф.М.Хөснуллин